**Марсель Бакиров**

филология фәннәре докторы, профессор.

# ЯРСУЛЫ ШИГЪРИЯТ

«Розалина – безнең өчен, дуслары һәм әдәбият сөючеләр өчен, иң әвәл – шагыйрә. Әйтергә кирәк, - ходайдан талант куәсе мул салынган зур шагыйрә» – хәзерге татар шигъриятен иңендә тотып торучы атлантларның берсе булган Равил Фәйзуллин заманында әлеге ханымга менә шундый мәртәбәле бәя биргән иде. Розалина Шаһиеваны һәм аның иҗатын олылаган фикерләр соңыннан Зөлфәт, Миргазиян Юныс һәм Рабит Батулла кебек башка олпат әдипләребезнең язмаларында да ассызыклап әйтелде.

Ләкин Розалинаның шигъриятен яшәеш һәм иҗатының икенче канаты булган сынлы сәнгать һәм сәнгать фәненнән аерып карау дөрес булмас иде. Ник дигәндә, аның дөньяга карашы, тирәлеккә эстетик мөнәсәбәтенең тернәкләнүе һәм камилләшүе турыдан –туры нәкъ менә сәнгать дөньясы белән бәйле. Бер-бер артлы Милли мәдәният музее, Бакый Урманче, Әмир Мәҗитов музейлары, Илдар Зарипов галереясы кебек сәнгатьханәләр ачып, бөртекләп аларның экспозицияләрен төзү, дөньяның төрле үзәкләрендә (Париж, Истанбул, Абу-Даби, Хельсинки, Будапешт) шаулатып татар сәнгате күргәзмәләре уздыру – болар барысы да Розалина башлап йөрүче һәм төп оештыру буларак катнашкан гаҗәеп җитди казанышлар! Әгәр боларга сәнгатькярнең Багдадта, Нью-Йоркта, Мәскәүдә, Санкт-Петербургта һәм уннарча башка шәһәрләрдә үткәрелгән форум һәм фәнни конференцияләрдә ясалган бай эчтәлекле доклад һәм чыгышларын, Казан татарларының гамәли бизәк ядкарьләренә, Татарстанның бүгенге көн сәнгатенә һәм танылган татар рәссамнарының иҗатына багышланган саллы альбом – монографияләрен, шулай ук күпкырлы мәдәни мирасыбыз турында төрле гыйльми җыентыкларда һәм журналларда басылган язмаларын да китереп кушсаң, Розалина Шаһиеваның ничәмә еллар буена милли мәдәният казанында кайнаганлыгын һәм милли сәнгать сандалында чүкелеп чарланганын тулырак һәм ныграк аңлыйсың. Шул ук вакытта, әлбәттә,

поэтик иҗатында ни өчен Шәрык белән Гареб традицияләрен үтә табигый һәм гармоник төстә бергә үрү сәбәбенә һәм дә үзенең гаҗәеп белемле, югары эрудицияле шәхес булу серенә дә төшенәсең. Өстәвенә ул немец, фарсы һәм төрек телләрен үзләштергән, рус һәм татар телләрендә бердәй дәрәҗәдә иҗат итә торган әдибә һәм ярым полиглот та. Менә шундый күпкырлы шәхес булганга һәм, өстәвенә, фарсы шагыйрьләрен татар һәм рус телләренә тәрҗемә иткән язучы булганга күрә, аның «Иран һәм җиһан» дигән Бөтендөнья шигърият конгрессында катнашуы һәм ике телдә шигырьләр укып, дәрәҗәле сертификат алуы бер дә гаҗәп түгел.

Розалина өчен шигърият – «тереклек суы, тәлгәш-тәлгәш милли сүз», «үлемсез моң чишмәсе» чын шагыйрь исә – «илнең асылташы, шигъри хикмәт әүлиясе, хәбәрчесе, рухы; аның моңын, утын саклаучы». Куш йөрәкле шагыйрә үзен һәм үзе кебекләрне «Тукай гөлләре без» дип атый. «Тәрәзәмә Тукай рухы чиртә» ди, хәтта аерым шигырьләрен аңа ияреп яза. Һәм иң мөһиме, «сөю, михнәт – синең рухыңда!» дигән хак бәясен биреп, үзе дә олуг шагыйрь сызган юлдан барырга омтыла.

Бер яктан, шагыйрә, чыннан да, туган җиренә һәм туган халкына мәдхия укый, аларга үзенең иң җылы хисләрен, ихлас сүзләрен багышлый:

- Йомычкадай алтын сүзләр тезеп
  Сөйдем йортым, болын, илемне.
- Шушы илдә – яр һәм ярам,
  Нәселем, утым, йорт-түбәм,
  Сукыр картларыңны үбәм
  Туфрак исним, җир үбәм.
- Ватанымның назын үлчәр өчен
  Аңа тиңдәш гөлләр эзләдем,
  Кошлар булып әверелдем күктә,
  Балык булып сулар гизләдем.
- Ыңгырашып аккан җырлар – безнең ил.
  Ә шулай да...

Нинди асыл безнең ил!

Сизгәнсеңдер, укучым, соңгы шигъри мисалда Ил-Йортның гүзәллегенә сагыш – ыңгырашу мотивы да килеп ялгана, дөресрәге, аңа капма-каршырак куела. Монысы инде шагыйрәнең күңелендә, чын иҗатчыларга хас булганча, яшәешкә, узган тарих һәм бүгенгегә мөнәсәбәтле канәгатьсезлек, ризасызлык тойгысының да тамыр җәйгәнлеге белән аңлатыла. Ризасызлыкның иң хатәре, әлбәттә, халкыбызның шанлы дәүләтен һәм милли азатлыгын югалту фаҗигасенә барып тоташа.

Үзем күрмәгәннәр канда кайный,
Ата-баба биргән кан аша –
Золым белән акыл якалаша,
Хөрлек белән коллык кайнаша.

Дәүләтчелекнең, хөррият һәм дини вөҗдан ирегенең юкка чыгуы реаль һәм трагик картиналарда төрлечә тасвирлана: Казан яулап алынганда шәһәрне саклаган ир-атның бүрәнәләргә бәйләп агызып җибәрелүен күрсәтү аша да («Казансуда ыңгыраша агайлар»), татарларны көчләп чукындыру белән шөгыльләнгән Аксак Каратун (архиепископ Лука Канашевич) образын җанландыру ярдәмендә дә («актарыла кара болыт – Каратун»), исән калган җирле халыкның чит илләргә качып китүен сурәтләү юлы белән дә («ят тарафка агалар тибәрелеп, сөрелеп»). Шушындый вәхшилекләрнең моһа кадђрге нәтиҗәсе һәм киләчәктә тәмам инкыйразга китерү куркынычы бик аянычлы, гыйбрәтле:

- Татар иле җиде якка калтая
  Ватан китә, тамыр кала, туңкаеп.
- Без яшәгән бәйрәм илен, Ниса,
  Бәгыреннән, тамырыннан кисеп,
  Кубаралар – аударалар, Ниса.
  Әгәр иман сүнеп, бары матдә генә
  Хөкемдарлык итсә җир йөзендә, Ниса,
  Киләчәкнең салкын бушлыгында

Ни дип гамәл итәр халкым, Ниса?

Татарның күп гасырларга сузылган милли һәм колониаль изелү, дини эзәрлекләнү фаҗигәсе Розалина Шаһиевага тынычлык бирми. Ул бу темага, төрле чорларны җанландырып, кат-кат әйләнеп кайта. Исемсез бер шигырендә Явыз Иван заманында эре җир биләүчеләр булып әверелгән Басмановларның берәүсе эшләгән вәхши вакыйга эпиграф итеп китерелә: «Яле, бәләкәчем, бир муеныңны, тәти муенса киертәм» дип, бу сабый баланы чала. Бәләкәй чагында үзе баздан табылган муенса киеп йөргән шагыйрәбез әлеге кара мәрҗәнне татарга янаучы инкыйраз символына әверелдерә һәм шунда ук билгесез киләчәкне өлкәннәр фатихасы белән бәйләп тә күзалларга омтыла.

Әллә элмәк, әллә мәрҗән,

Татар дигән бу муенса?!

Баба күзе, ана сүзе – киләчәгем,

Насыйп булса.

Халкыбызның тарихи хәтере белән аваздаш булганга күрә дә, шагыйрә Идегәй, Мөхәммәдьяр, Кол Шәриф, Сөембикәләрне, кадерләп, шигърияте түренә иңдерә. Хәтта романтик тоемлавын эшкә җигеп, аларны хәзерге заман үзгәрешләре белән бәйли. Аңа монда чуваш фольклорында сакланган тарихи легенда ярдәмгә килә. Баксаң, Сөембикә-ханбикә манарадан сикереп үлмәгән, Шаһгали зинданында да гомере киселмәгән, ә Казанын баскынчылардан азат итәргә дип – гаскәр җыю өчен – үзе төзеткән манарадан, аккошка әйләнеп, очып киткән икән.

«Ирек!» дип күкрәгәндә Казан халкы,

Хан мәчете өсләреннән оча икән

Аккош булып, бертуктаусыз сагыш булып,

Милли дәһшәт, агыш булып,

Сөем-сөем-Сөембикә.

Милли-милли-миллионнар

«Азатлык!» дип ураганда

Биналарны, мәйданнраны –

Кагынадыр канатларын

каурый болыт – Сөембикә.

Ашкынулы романтик табигате Розалина Шаһиевага заманында «җәнҗаллы диварлар», сәяси репрессияләр шаһите булган Черек күлдә ялкынлы шигырьләр укыта, гыйсьянчыга әверелдереп («Фауст уты дөрли күкрәктә!»), биленә «кылыч буып, көбә кидертә», җәннәткә кертеп, татарның милләтпәрвәр шагыйрьләре, туган-тумачасы һәм дөньялыкта кавышырга насыйп булмаган җанашы белән очраштыра. Әлбәттә инде, авторның иң матур, иң җылы сүзләре үзен татар җанлы итеп үстергән дәү әнисенә һәм әтисенә юнәлтелә. Серле җанкай-җанашына багышланган метафоралары исә игътибарны үтә тәэсирле һәм оригиналь булулары белән җәлеп итә:

- Кулыма кагылган зур учыңда
  Кояш булган, –
  Кайнар шәраб кебек, дулап,
  Кереп киткән иде кан юлыма.
- Кавышмасак,
  Бу дөньяның тәме бетәр,
  Сүлпәнәер кояш,
  Йөзтүбән коелыр йолдызлар.

Шунысы характерлы: әдибә бердәй дәрәҗәдә бик-бик нечкә хисле дә, ирләрчә кырыс та һәм хәтта усал да була белә. Башбаштаклык һәм социаль гаделсезлек хөкем сөргәндә борчыла белмәү, күрмәмешкә салышып читтә җан асрау – аның өчен җинаять! Шундый чакта «качып-посып акыл сату» да – пассивлык, куркаклык.

Без, сыкранып, тирес катламыннан

Җәүһәрләрен илнең бакканда,

Кяферләнгән гариб нарасыйлар

Бер-беренә уклар атканда,

Җәберләнгән динем, дәрт, иманым

Сөргеннәрдә газап чиккәндә,

Кайда булдың? Нигә сискәнмәдең

Идел суы ишек какканда?

Автор бу сүзләрне шагыйрь исеме күтәреп йөргән икейөзле, куштан танышының йөзенә бәреп әйтә һәм үтергеч юллар белән аңа үз бәясен бирә:

Борча булып, парча язып яттың,

Пәрдә кордың күзең күрмәскә.

Яки менә шагыйрәнең, сөрән салып һәм дәлилләп, ялган тарих язучыларны фаш иткән юллары:

Ал сөртмәгез минем тарихыма,

Күпме кайгы анда, бәддога.

Ләкин, белүебезчә, ата-бабаларыбыз тарихында горурланырлык шәхесләр бар. Автор аларны да читләтеп үтми, тарихның «чабышкы-арба»сына утырып, Аттила, Чыңгызхан дәверләренә барып чыга һәм аларга, Пушкинның «Кечкенә трагедияләр»е кебек, шигъри һәм героик трагедияләрен багышлый. Заманыда Кытай белән Идел-Йортны тоташтырган атаклы ефәк юлына һәм сәүдә караваннарына арналган шигыре исә – узганннарга ода-мәдхия. Шул ук вакытта шагыйрә, бүгенге яшь буынны «борынгыларның хәләл мирасы, ата-бабаларның амәнәте, фатихасы, догасы»на турылыклы булырга чакыра һәм хәзерге мәдәни казанышларны узган традицияләр белән бәйли.

Гомумән, Розалина – ватанының, халкының кан тибешен сизгер тоя торган, актив позицияле һәм һәрнәрсәдә эше, катнашы бар талант иясе. Тукай әйтмешли, аның күзе күпне күрә, колагы күпне ишетә. каләме болгавыр заман галәмәтләрен оста тасвирлый. Кыргый капитализм чорында алып-сатуга корылган базар мөнәсәбәтләрен һәм бүгенге мораль бозыклык корбаннарын автор хәтта бер каләм тирбәтүдә үк сурәтләп бирә:

- Җан керүгә шәһәр урамына,
  Мең еллыгын бәйләп башына,
  Әпчи карчык Казан, тартма тартып,
  Печән базарына ашыга.
- Әнә картлач урам себеркесе – «Кармен» –
  Елый-елый, көлә-бии бөтерелә.

Тормыш аны әйләндергән «үрмәкечкә»...
Сәрхүш гәүдәләре белән түнә-түнә,
Әйләнә ул, әйтерсең лә Штраус монда.

Мөхит үзгәрешләрен чагылдыручы менә шундый җанлы манзаралар тудыру, аларны Ауропа реалияләре белән үреп гәүдәләндерү осталыгы, әлбәттә, әдибәнең Көнчыгыш мәдәнияте һәм рәсем сәнгате белән бәйләнешле сурәтле хәрәкәтсез фикерләвеннән килә. Миңа калса, аның хәрәкәтсез-статик һәм хәрәкәтле яки җанлы детальләрдән һәм төрле төшенчәләрдән, эмоциональ халәтләрдән тукылган микрообразларны бер җепкә тезәргә яратуы да – поэтик стиль үзенчәлеге. Мондый поэтик сурәтләр, куыша-куыша тәгәрәүче дулкыннар кебек, бер-берсен куәтләп киләләр, көтелмәгән ассоциацияләр тудыралар.

- Су чайкала, хисләр ургый, җан сызгыра.
- Инкыйразлар, җәнҗал, яңарышлар
  Мәрҗән кебек килә тезелеп.
- И Ходам, синең зиннәтең,
  Дөнья тудыру михнәтең,
  Галәмгә өргән иҗатың –
  Гөмбәзең, дәрьяң, җәннәтең,
  Иңдергән рухи җәүһәрең,
  Китабың – акыл шәһәрең,
  Мәдхиягә тезәм барын –
  Тәсбих итәм корбаннарың.

Чынбарлыкны капма-каршылыклар дулкынында чагылдыра торган Розалина Шаһиева иҗатының төп лейтмотивы, әлбәттә, матурлык џђм матурлыкны яклау. Ул үзе дә: «Бер сыйфатын тойдым бу дөньяның – бар халәткә кадәр ямь элек! » дип, шуңа басым ясый. Ямь-матурлыкның «өч кит»ы, алтын баганалары исә, шагыйрә бик дөрес искәрткәнчә, «мәдәният, ислах, хөррият». Шуларга бәйләп, ул халкына ялкынлы чакыру ташлый: «Сакла хөрриятең... татар, алдан бар! Аллаң бар!» ди. Автор шулай ук Ватаны, халкы алдындагы миссиясенә үзенең турылыклы булуын да искәртә:

Бул син, йөрәк,
Миңа терәк –

Илпәрвәр, ватанпәрвәр!